РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН

ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
ГОРОДА АЗНАКАЕВО
АЗНАКАЕВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ул.Ленина, д.14, г.Азнакаево, 423330

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ

АЗНАКАЙ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
АЗНАКАЙ ШӘҺӘРЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

Ленин ур.,14 нче йорт, Азнакай ш.,
423330

Тел./факс(885592)7-15-50,7-00-37; E-mail:aznakay@tatar.ru, adm-aznakay@mail.ru;
http://aznakayevo.tatarstan.ru/

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

02.04.2025 ел. № 08

Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 10 декабрендәге 34 номерлы «Азнакай шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләрдән (фейерверклар) файдалануны тәртипкә салу чаралары турында»гы карарына үзгәрешләр һәм өстәлмәләр кертү хакында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2010 елның 11 мартындагы «Россия Федерациясе һава киңлеген файдалануның федераль кагыйдәләрен раслау турында»гы 138 номерлы карары нигезендә, Кама транспорт прокуратурасының 2025 елның 27 февралендәге №23/1-02-2025 протестын исәпкә алып:

1. Татарстан Республикасы Азнакай муниципаль районы Азнакай шәһәре Башкарма комитетының 2021 елның 10 декабрендәге 34 номерлы «Азнакай шәһәре территориясендә пиротехник эшләнмәләрдән (фейерверклар) файдалануны тәртипкә салу чаралары турында»гы карарына 3 пунктка түбәндәге эчтәлекле бишенче абзацны өстәп, үзгәрешләрне кертергә:

“Бердәм системаның оператив органы (“Үзәк Идел Аэронавициясе” Филиалы) “Һава хәрәкәтен оештыру буенча дәүләт корпорациясе”, 443901, Самара өлкәсе, Самара шәһәре, “Курумоч” аэропорты) федераль дәүләт унитар предприятиесе 50 метрдан артык биеклектәге салют һәм фейерверклар үткәргәндә һава киңлекләрен куллану буенча, шулай ук салют һәм фейерверклар биеклегенә карамастан, җир яки су өслегенә һава алымнары полосалары проекциясе чикләрендә һава киңлекләрен куллану буенча рөхсәт алынды.

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында түбәндәге веб-адрес буенча урнаштыру юлы белән игълан итәргә: http://pravo.tatarstan.ru һәм Азнакай муниципаль районының рәсми сайтында Интернет "мәгълүмат-коммуникацион челтәрендә түбәндәге веб-адрес буенча» урнаштырырга: http://aznakaevo.tatarstan.ru.

3. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

Җитәкче Э.Ә. Габдрахманов